**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2018 ел, 14 декабрь №134

**“Физик затларның мөлкәтенә салым турында” карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 94 номерлы “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

2.2.Физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балалары.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1)фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә, торак йорт, торак йортның бер өлеше;

2)гараж, машина урыны.

Салым ташламасы авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) салым түләүчеләргә салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы размерында бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.”;

Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр салым органына бирелә.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Сатмыш авыл**
**җирлеге башлыгы Р.Р.Сибгатова**